

28 ноябрьдә Республика матбугат vзәгендә Мордовия халкын пенсия һәм социаль тәэмин итvнен актуаль мәсьәләләренә багышланган матбугат конференциясе узды. Чара башында Россия Социаль фондынын Мордовия Республикасы буенча бvлеге идарәчесе Владимир Ильич Василькин 2024 елнын 27 гыйнварында Ленинградның фашист блокадасыннан тулысынча азат ителvенә 80 ел тулуны билгеләп vтте. Бу елнын сентябрендә Россия Президенты «Ленинградны саклаган очен» медале яки «Блокадалы Ленинградта яшәvче» билгесе белән бvләкләнгән гражданнарга бер тапкыр тvләv турында Указга кул куйды. Документ нигезендә, аларга 50 мен сум акча каралган. Мордовиядә бvгенге кондә мондый тvләvгә 12 пенсионер хокуклы. Kvрсәтелгән сумманы алар декабрьдә алачак. Матбугат конференциясендә СВО катнашучыларына ярдәм итv чаралары турында да сойләштеләр. Мәсәлән, тиешле таныклыгы булган сугыш хәрәкәтләре ветераннарына социаль фонд линиясе буенча ай саен 3 мен 896 сум kvләмендә акчалата тvләv каралган. Хәрби травма аркасында инвалидларга ай саен 7 мен сум акча билгеләнә. Остәвенә, инвалидлык торкеме моһим тvгел.

«Мондый социаль ярдәм чараларына СВОда катнашучылар коч ведомстволары линиясе буенча тvләvләр билгеләнvгә карамастан хокуклы, - дип остәде Владимир Ильич Василькин. - Моннан тыш, без аларга башка социаль гарантияләр дә бирәбез. Мәсәлән, махсус операция нәтижәсендә инвалид булган хәрбиләр техник реабилитация чаралары белән тәэмин ителергә хокуклы».

Шулай ук махсус операциядә катнашучыларнын гаиләләренә ярдәм kvрсәтелә. Мәсәлән, мобилизацияләнгән кешенен гаиләсе хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрнен баласына айлык пособие алырга хокуклы. Әгәр срочная хезмәткә чакыру вакытында мобилизацияләнгән кешенен хатыны йокле булса, мондый гаиләгә 36 мен 278 сум kvләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие тvләнәчәк. Моннан тыш, социаль фонднын vз бvлеге катнашучыларнын гаиләләренә балаларга карата берничә пособиене гадиләштерелгән тәртиптә билгели, олешчә мобилизация барышында чакырылганнарнын керемнәрен исәпкә алмыйча.

Матбугат конференциясендә олкән буын аралашу vзәкләре темасы да kvтәрелде. «Узган елнын козендә Россия Пенсия фонды клиент хезмәтләре мәйданчыкларында пенсионерлар очен аралашу vзәкләре фонды булдыру буенча пилот проектын vткәрv концепциясен эшләде. Лаеклы ялга чыккан кешегә җәмгыять белән элемтәләрне саклау һәм vз-vзен тормышка ашыру момкинлеге булу моһим. Актив озын гомер очен шартлар тудыру дәvләтнен топ бурычларынын берсе һәм Россия Социаль фонды эшчәнлегенен остенлекле юнәлешләренен берсе булып тора», - диде Владимир Ильич Василькин.

Бvгенге кондә Мордовиядә шундый 17 vзәк ачылган. Алар Дубенка, Атяшево, Ардатов, Рузаевка, Темников, Ковылкино, Инсар, Чамзинка, Теньгушево, Зубово Поляна, Большеберезняк, Лямбирь, Торбеево, Ичалки, Атюрьево, Кочкурово һәм Ельникта эшлиләр.

Очрашу ахырында Владимир Ильич Василькин Мордовия халкынын барлык сорауларын Кайнар линия телефоны аша бирергә момкинлеген искәртте: 8 800 200 01 88.

Наилә НАСЫРОВА